ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

21 05 2021 г. № 501

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 5 сентябрендәге 551 номерлы карары белән расланган «Балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары нигезендә, шулай ук муниципаль функцияләрне үтәүне оптимальләштерү һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын арттыру максатларында, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 5 сентябрендәге 551 номерлы карары белән расланган «Балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне кушымта нигезендә расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмасында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 21 нче май
501 нче номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының
2017 елның 5 сентябрендәге 551 номерлы карары белән расланган «Балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1. 1.3 пунктны төшереп калдырырга;

2. 1.4.1 пунктында «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» сүзләрен «Яшьләр эшләре идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

3. 1.5.1 пунктының икенче абзацында, 1.6.2 пунктының икенче абзацында «47-32-10» сүзләрен «43-08-42» сүзләренә алмаштырырга;

4. 1.6.1 пунктының икенче абзацында «Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсенә» сүзләрен «Яшьләр эшләре идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

5. 1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата - муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе) до-кументтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районы шәһәр яки авыл җирлегендә (шәһәр округында) төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис);

муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза (алга таба – гариза) - муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату (27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза ирекле формада, Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк буенча яки стандарт бланкта тутырыла (5 нче кушымта).

6. «Стандартка таләпләр эчтәлеге»нең 2 бүлеген түбәндәге кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

7. 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, Башкарма комитет вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган эшләр башкаруны алып баруны тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (Башкарма комитет эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда, муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр дә карала ала.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең үтәлешен контрольдә тоту максатыннан, Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Башкарма комитет җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплылык тота.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тота.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.».

8. 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар-ның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт бирүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Башкарма комитетка судка кадәр шикаять бирү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.1 һәм 11.2 статьяларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә шикаять белән мөрәҗәгать итә ала.

5.2. Башкарма комитет, Башкарма комитетның вазыйфаи заты, муниципаль хезмәткәр, Башкарма комитет җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүченең шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтла-рын, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яисә дәүләт һәм муни-ципаль хезмәт күрсәтүләрнең региональ порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул итүендә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьтә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән белешмәләр булырга тиеш. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять, шул исәптән, кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән төгәлсезлек һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында алу каралмаган акчаны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару рәвешендә дә канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.4. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.5. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 8 өлешендә күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта учреждение, күпфункцияле үзәк яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма тарафыннан, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук бирелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.6. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 8 өлешендә күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә күрсәтелгән шикаять карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.».

«Балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләргә
1 нче кушымта

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге |
|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы | Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру |
| 2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органы атамасы | Яшьләр эшләре идарәсе исеменнән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Балалар сәламәтләндерү лагерена юллама.<br>Юллама бирүдән баш тарту |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Муниципаль хезмәт 1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр ТР Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең еллык карарлары нигезендә күрсәтелә. Муниципаль хезмәт смена башланганчы 14 көн эчендә күрсәтелергә тиеш. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. |
| 2.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүнең хокукый нигезләре | Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:<br>- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон), (РФ законнары җыелмасы, 06.10.2003, № 40, 3822 ст.);<br>- «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 124-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 03.08.1998, № 31, 3802 ст.);<br>- «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 5 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 08.05.2006, № 19, 2060 ст.);<br>- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);<br>- «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы законы) (Известия Татарстана, № 233, 27.11.1993);<br>- «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы( алга таба – ТР Законы № 16-ТРЗ) (Татарстан Республикасы, № 111, 02.08.2014);<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 346 номерлы карары) (Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, № 35, 0940 ст.); |

| | |
|---|---|
| | - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 елның 3 мартындагы 130 номерлы карары (алга таба - ТР МК 130 номерлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы), 17.03.2015, № 21, 0711 ст.);<br>- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав) |
| 2.6. Законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә, мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документларга һәм мәгълүматка һәм мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы документларга бүлеп, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге | I. Юллама алу өчен гариза бирүче тарафыннан тапшырыла:<br>1) гариза (әлеге Регламентка 5 нче кушымта);<br>2) бер әти-әнинең (законлы вәкилнең) паспорт күчермәсе (төп нөсхәне күрсәтеп);<br>3) граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе (төп нөсхәне күрсәтеп);<br>4) ата - аналарның берсе (законлы вәкил) эш урыныннан юллама өчен түләү буенча ташламалар каралган затлар өчен белешмә;<br>5) баланың уку урыныннан белешмә;<br>6) баланың медицина тикшерүе узуы турында белешмә;<br>7) юллама өчен түләү турында квитанция;<br>8) путевка бирү өчен ташламалы нигезләрне раслаучы документлар (булганда).<br>II.Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документлар (белешмәләр) алына:<br>-граждан хәле актлары язмаларының бердәм дәүләт реестрыннан бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр. |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) муниципаль хезмәт күрсәтүче оешмаларны гамәлдән чыгару яки үзгәртеп кору;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтүче оешмада аның ялына комачаулаучы баланың хәле турында медицина бәяләмәсе булу;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтүче оешмаларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен муниципаль хезмәт күрсәтү алучы тарафыннан берничә тапкыр (ике һәм аннан күбрәк тапкыр) бозу;<br>4) хезмәт күрсәтүче оешмаларда урыннар булмау;<br>5) муниципаль хезмәт күрсәтүче оешмага бәйле булмаган форс-мажор шартлары булу, аерым алганда, җир тетрәү, су басу, янгын, хәрби гамәлләр һәм күзәтчелек органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне тыю гамәлләре. |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә кабул ителгән федераль законнарда каралган очракларда аны алу ысуллары | Түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең еллык карары нигезендә билгеләнә |

| | |
|---|---|
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда, чират көтүнең максималь вакыты | Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату биргәндә, гариза бирүчеләрнең көтү вакыты унбиш минуттан артмаска тиеш |
| 2.11 Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соратуын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соратуын теркәү кергән вакыттан 15 минут эчендә башкарыла<br>Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә кергән сорату ял (бәйрәм) көненнән соң килүче көндә теркәлә |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарына, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату тутыру урыннарына, һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тутыру үрнәкләре булган мәгълүмат стендларына, шул исәптән, инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда башкарыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озатып йөрүче этләрне файдаланучыларга, бинадан, урыннардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:<br>- бинага һәм урыннарга, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;<br>- элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар;<br>- объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре нык бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм урыннарда ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, биналарга, урыннарга һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;<br>-инвалидлар өчен кирәкле тавышлы һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- аны махсус укытуны раслый торган һәм халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә торган форма һәм тәртиптә бирелә торган документ булганда, озатып йөрүче этне бинага һәм урыннарга кертү;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәт алуга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү. |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге Башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү чиратлары; |

| | |
|---|---|
| | муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Башкарма комитетта алынырга мөмкин. |
| 2.14. Башка таләпләр, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала. | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эш урыннары аша муниципаль хезмәт күрсәтү башкарылмый.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорату составында муниципаль хезмәт күрсәтелми.<br>Башкарма комитетта муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультация алырга мөмкин.<br>Әгәр закон нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелә (http://uslugi. tatarstan.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (http:/ www.gosuslugi.ru/) аша бирелә |